# 1 САНЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

02 декабрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 21 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта, 2019 елның 22 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2019 елның 23 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (Өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча этаплап гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) Ямаширмэ торак пунктына балалар площадкасы алу ;
б) Ямаширмэ торак пунктында һәйкэл ремонтлау;
в) Ямаширмэ торак пунктында контейнер площадкасын койма белэн эйлэндеру;
г) Ямаширмэ торак пунктында карт, черегэн агачларны кисү;
д) Ямаширмэ торак пунктында кышкы кардан юлларны чистарту;
е) Ямаширмэ торак пунктындагы юлларны ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 873 (сигез йөз житмеш өч) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 452 (дурт йөз илле ике) кеше, бу 51,78%ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 438 (дурт йөз утыз сигез) катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 14 (ундүрт) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү

урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (Өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?"

а) Ямаширмэ торак пунктына балалар площадкасы алу ;

б) Ямаширмэ торак пунктында һәйкэл ремонтлау;

в) Ямаширмэ торак пунктында контейнер площадкасын койма белэн эйлэндеру;

г) Ямаширмэ торак пунктында карт, черегэн агачларны кисү;

д) Ямаширмэ торак пунктында кышкы кардан юлларны чистарту;

е) Ямаширмэ торак пунктындагы юлларны ремонтлау"- дигэн мэсьэлэ буенча кабул ителгэн дип санарга.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ямаширмэ авыл җирлеге башлыгы — Ф.К.Мухтаров